МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

07.06.2019 Казан ш. № 1801-р

**Газ бүлү челтәрләренең (газүткәргечләр) саклау зоналары чикләрен үзгәртү Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 07.08.2014 № 1620-р карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Җир Кодексының 56 ст., «Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында» 1999 елның 31 мартындагы № 69-ФЗ Федераль законга, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары белән расланган Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләренә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Газ бүлү челтәрләренең саклык зоналары чикләрен раслау турында карарлар кабул итү тәртибен раслау һәм аларга керә торган җир кишәрлекләренә чикләүләр (йөкләүләр) кертү турында” 30.04.2014 № 288 карарына туры китереп һәм «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖ мөрәҗәгате һәм газ бүлү челтәрләренә милек хокукын раслаучы документлар нигезендә, һәм «Компания кадастровый Инженер» ҖЧҖ башкарган документациягә туры китереп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 22.08.2007 ел, № 407 карары белән расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турында нигезләмәсенә таянып, Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы (алга таба – ТР Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы) КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының “Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә газ бүлү челтәрләренең (газүткәргечләр) саклау зоналары чикләрен раслау турында” 07.08.2014 № 1620-р карары (алга таба - № 1620-р Карар) белән “Казан шәһәре” муниципаль берәмлеге, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә урнаштырылган, «Газпром трансгаз Казань» (ЭПУ «Приволжскгаз») милкендә булган, 9131 инвентарь номерлы бүлгеч газүткәргечнең 15198,21 кв.м гомуми территориядәге 7684,08 м озынлыктагы өлешендәге әлеге карарның кушымтасында күрсәтелгән саклау зонасын газүткәргечнең демонтажы сәбәпле бетерергә.

2. «Газпром трансгаз Казань» (ЭПУ «Приволжскгаз») милкендә булган, “Казан шәһәре” муниципаль берәмлеге, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә урнаштырылган, 7924,08 м озынлыктагы, гомуми мәйданы 20679,03 кв.м.лы территорияне тәшкил иткән, инвентарь номеры әлеге карарның 2 нче кушымтасында күрсәтелгән газүткәргечнең әлеге карарның 3 нче кушымтасына туры килгән җир кишәрлекләре өлешен, газүткәргечләр демонтажлану сәбәпле, һәм территорияне файдалануның аерым шартлары булган зоналар чикләренең текст һәм график тасвирламасы, «Компания Кадастровый инженер» ҖЧҖ тарафыннан 2018 елның августында әзерләнгән җир өсте һәм җир асты объектларының характерлы нокталары координаталары исемлегенә нигезләнеп саклау зоналары чикләрен расларга.

3. Инвентарь номеры 9131 булган газүткәргечләрнең саклау зоналары чикләренә тулысынча яки өлешчә туры килгән һәм әлеге карарның 2 нче кушымтасында күрсәтелгән җир кишәрлекләренә газүткәргеч өлешләрен эксплуатацияләү срогына Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары белән расланган газ бүлү челтәрен саклау кагыйдәләрендә каралган чикләүләр (йөкләүләр) кертергә.

4. Территорияне файдалануның аерым шартлары булган зоналар чикләренең текст һәм график тасвирламасы, «Компания Кадастровый инженер» ҖЧҖ тарафыннан 2018 елның августында әзерләнгән җир өсте һәм җир асты объектларының характерлы нокталары координаталары исемлегенә нигезләнеп № 1620-р Карарга түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

атаманы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы «Казан шәһәре» муниципаль берәмлеге, Лаеш муниципаль районы территориясендә газ бүлү челтәрләренең (газүткәргечләр) саклау зоналары чикләрен раслау турында»;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. “Казан шәһәре” муниципаль берәмлеге, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә урнаштырылган, 952,345 км озынлыктагы, гомуми мәйданы 3,80961682 кв.км территорияне тәшкил иткән, инвентарь номеры әлеге карарның 1 нче кушымтасында күрсәтелгән ЭПУ «Приволжскгаз» газ бүлү челтәренең (газүткәргечләрнең) «Компания Кадастровый инженер» ҖЧҖ тарафыннан 2013 елның 3 июненнән 2013 елның 13 декабренә кадәр әзерләнгән һәм «Газпром трансгаз Казань» тарафыннан 2013 елның 31 декабрендә килештерелгән территорияне файдалануның аерым шартлары булган зоналар чикләренең текст һәм график тасвирламасы, җир өсте һәм җир асты объектларының характерлы нокталары координаталары исемлегенә нигезләнеп саклау зоналары чикләрен расларга.»;

1 нче кушымтаның 24 юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 24 | 9131 | | Татарстан Республикасы, Казан ш., Идел буе р-ны, Петровский т.р; ТР, Лаеш районы, Комлы Ковал ав. | 924,08 | d=110<br>Урта басым | 16:24-5:2001-1490.1<br>от 30.11.2001 |

16:24:090704:80, 16:24:090102:104, 16:24:090111:120, 16:24:090704:86, 16:24:090704:128, 16:24:090704:223, 16:24:090704:83, 16:24:090704:643, 16:24:090704:801, 16:24:090111:628, 16:24:090111:713, 16:24:090301:287, 16:24:090704:61, 16:24:090704:80, 16:24:090704:95, 16:24:090301:193, 16:24:090301:2951, 16:24:090704:246, 16:24:090301:3004, 16:24:090301:3006, 16:24:090301:3237, 16:24:090301:3238, 16:24:090301:3239, 16:24:090301:3240, 16:24:090301:3236, 16:24:090704:875 кадастр номерлы җир кишәрлекләренә туры килгән юлларны 2 нче кушымтадан төшереп калдырырга;

әлеге карарның 2 кушымтасына туры китереп, 2 нче кушымтаны тулыландырырга.

5. «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖга тәкъдим итергә:

1) әлеге карарның 1, 2 пунктларында газүткәргечләрнең саклау зоналары турында төгәлләштерелгән белешмәне Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрына кертү чараларын күрергә;

2) газүткәргечләр демонтажлану сәбәпле әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән җир кишәрлекләре өлешләрендә булган чикләүләрнең туктатылуы турында белешмәне Күчемсез милек бердәм дәүләт реестрына кертү чараларын күрергә;

3) әлеге карарның 3 пунктында күрсәтелгән җир кишәрлекләренә булган чикләүләрне Күчемсез милек бердәм дәүләт реестрына кертү чараларын күрергә;

4) әлеге карар кабул ителүгә 5 көн эчендә карарны, электрон формада әзерләнгән территорияне файдалануның аерым шартлары булган зоналар чикләренең текст һәм график тасвирламасын, әлеге карарның 2 пунктында күрсәтелгән газүткәргечнең характерлы нокталары координаталары исемлеген беркетеп, реестр хаталарын төзәтү аркасында газүткәргеч өлешләренә элек куелган саклау зоналары үзгәрү турында белешмәне күчемсез милек бердәм дәүләт реестрына кертү өчен хокукларны регистрацияләү органына юлларга.

6. Әлеге карарның башкарылуын контрольдә тотуны министрның беренче урынбасары А.И.Галиевка йөкләргә.

**Министр** **А.К.Хамаев**